ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.03.2023 Олы Кайбыч ав. № 83

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгын финанслау керемнәренең һәм чыганакларының төп администраторлары исемлеген раслау турында» 2022 елның 14 декабрендәге 546 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгын финанслау керемнәренең һәм чыганакларының төп администраторлары исемлеген раслау турында» 2022 елның 14 декабрендәге 546 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтада:

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы бүлегендә түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 926 | 11107015050000120 | Муниципаль районнар тарафыннан төзелгән муниципаль унитар предприятиеләрнең салымнар түләгәннән һәм башка мәҗбүри түләүләреннән соң калган табыш өлешен күчерүдән керемнәр |

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Н.Макаров